ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАЛМИЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАР

24.02. 2021 ел №5

«Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегенең Кырныш авылында 2021 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Калмия авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

**Карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Калмия авылы, Яшьләр урамы, 23 нче йорт адресы буенча урнашкан Калмия мәдәният йорты бинасында Тукай муниципаль районының Калмия авыл җирлегенең Кырныш авылы гражданнарының 2021 нче ел өчен үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 6 мартына 16:00 сәгатькә билгеләргә..

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегенең Кырныш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә риза буласызмы?:

а) Карардагы «**500 сум күләмендә**» сүзен **, «<u>1000 сум</u> күләмендә сүзләренә алмаштырырга**»;

б) Карарда сүзләр:

1) юлларны ремонтлау, вак таш сатып алу, махсус техника хезмәтләре күрсәтү,

2) урам утларын урнаштыру, монтажлау, электр җиһазлары сатып алу һәм комплектлау элементларын - «**Кырныш торак пунктында спорт мәйданчыгы, керү юлы һәм әлеге спорт мәйданчыгында яктырту»** сүзләренә алмаштырырга.

«ӘЙЕ» « КАРШЫ»

3.Әлеге карарны Калмия авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән, Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (http:// tukay.tatarstan.ru.), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:/pravo. tatarstan. ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Тукай муниципаль районы
Калмия авыл җирлеге башлыгы Р. Ә. Гарипов